| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧУТЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧҮТИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 январь 2023 ел Чүти ав. № 1

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 7793,48 сум күләмендә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы ««Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 1 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә https://chuteev-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе П.П.Тараканов

Чүти авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 е. «30» январенең
1 номерлы карарына
1нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек буенча хезмәтләр күрсәтүнең бәясе**

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумга. ) |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3343,60 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 895,12 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3554,76 |
| Барлыгы | **7793,48** |

Чүти авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 е. «30» гыйнварендагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек буенча хезмәтләр күрсәтүнең бәясе**

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумга. )** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 420,34 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2923,26 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 895,12 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3554,76 |
| Барлыгы | 7793,48 |